КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 4 декабрь г.Казань № 1095

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен раслау турында» 2011 ел, 4 ноябрь, 917 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен раслау турында» 2011 ел, 4 ноябрь, 917 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2014 ел, 8 октябрь, 733 нче; 2015 ел, 7 август, 574 нче; 2016 ел, 1 сентябрь, 608 нче; 2017 ел, 16 гыйнвар, 10 нчы; 2018 ел, 23 апрель, 280 нче, 2019 ел, 22 октябрь, 951 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу буенча» сүзләрен «җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләре өлкәсендә җайга салу» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Җир асты байлыкларыннан файдаланучылар булып эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары, шул исәптән гади ширкәттә катнашучылар, чит ил гражданнары, юридик затлар, шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен

товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон яисә «Юридик затларның аерым төрләрендә товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен башкаруга граждан-хокукый шартнамәләр төзелгән юридик затлар булырга мөмкин, әгәр федераль законнар белән башкасы билгеләнмәгән булса.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен файдалануга яисә аларны геологик өйрәнүнең, разведкалауның һәм чыгаруның берләштерелгән лицензиясе буенча гамәлгә ашыру өчен, җир асты суларын эзләү һәм аларга бәя бирү максатларында геологик өйрәнү өчен, җир асты суларын разведкалау һәм чыгару өчен яисә җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү, җир асты суларын чыгару өчен, эчәр сулар белән тәэмин итү яисә коммерциячел булмаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яисә) коммерциячел булмаган ширкәтләрне техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган җир асты суларын чыгару өчен, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле максатларында геологик өйрәнү өчен «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм әлеге Тәртип белән билгеләнгән тәртиптә.

Җир асты шулай ук авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү һәм шундый файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен бер үк вакытта файдалануга бирелергә мөмкин. Җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы аларга карата авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү өчен бирелергә мөмкин җирле әһәмияттәге авыр чыгарыла торган файдалы казылмалар төрләре федераль законнар нигезендә билгеләнә.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре җир асты байлыклары турындагы законнар нигезендә билгеле бер срокка яисә срокны чикләмичә файдалануга бирелә.

Җир асты байлыклары кишәрлекләре билгеле бер срокка түбәндәгеләр өчен файдалануга бирелә:

геологик өйрәнү - 5 елга кадәр вакытка;

файдалы казылмалар чыгару - җир асты байлыкларыннан рациональ файдалануны һәм аларны саклауны тәэмин итә торган файдалы казылмалар ятмаларын чыгаруны техник-икътисадый нигезләүдән чыгып исәпләп чыгарыла торган файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү чорына;

җир асты суларын чыгару - 25 елга кадәр вакытка;

файдалы казылмалар чыгару җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануның кыска сроклы хокукы бирү нигезендә, шулай ук җир асты байлыкларыннан рациональ файдалану һәм аларны саклау мәнфәгатьләрендә

файдалы казылмалар чыгаруны туктатып тору максатка ярашлы булмаса яисә җир асты байлыкларыннан яңа файдаланучы турында карарны билгеләнгән тәртиптә «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының $21^1$ статьясы нигезендә кабул ителгәнчегә кадәр - 1 елга кадәр вакытка;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә гомумтаралган файдалы казылмалар булган һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертелгән, алар Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тарафыннан расланган Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертелгән һәм «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының $10^1$ статьясындагы 6 пунктының сигезенче абзацы нигезендә файдалануга бирелә - гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту буенча эшләрне башкару вакытына;

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының $10^1$ статьясындагы 3 пунктының сигезенче абзацы нигезендә авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү - 7 елга кадәр вакытка, ә «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 101 статьясындагы $4^1$ пункты нигезендә – авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, эзләү һәм чыгару технологияләрен эшләү өчен $^1$5 елга кадәр вакытка.

Файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен, калдыкларны күмүгә бәйле җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен, нефть һәм газ саклагычларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен, тау токымнары катламнарында юлдаш суларны, углеводород чималын разведкалаганда һәм чыгарганда үз җитештерү һәм технологик ихтыяҗлары өчен җир асты байлыкларыннан файдаланучылар тарафыннан файдаланылган суларны, разведка һәм чыгару белән шөгыльләнүче, шулай ук калий һәм магний тозларын беренчел эшкәртүче җир асты байлыкларыннан файдаланучылардан барлыкка килә торган суларны урнаштыру өчен, махсус саклана торган геологик объектлар төзү һәм башка максатлар өчен җир асты байлыклары кишәрлекләре вакытын чикләмичә бирелергә мөмкин.

Җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану срогы җир асты байлыкларыннан файдаланучы инициативасы буенча файдалы казылмалар ятмасын эзләү һәм бәяләү яисә эшкәртүне төгәлләү кирәк булган очракта йә җир асты байлыкларыннан файдаланучыга лицензия шартлары бозылмаган очракта, ликвидация чараларын үтәү буенча озайтыла.

Продукцияне бүлү турындагы килешү шартларында җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану срогын озайту тәртибе күрсәтелгән килешү белән билгеләнә.»;

8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының $10^1$ статьясындагы 3 пунктының сигезенче абзацы

нигезендә файдалануга бирелгән җир асты байлыклары кишәрлегендә геологик өйрәнү, разведкалау һәм авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны чыгару технологияләрен эшләү срогы җир асты байлыкларыннан файдаланучы инициативасы буенча авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү кирәк булган очракта бер тапкыр 3 елга кадәр вакытка озайтыла. «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының $10^1$ статьясындагы $4^1$ пункты нигезендә файдалануга тапшырылган җир асты байлыклары кишәрлегендә геологик өйрәнү, разведкалау һәм авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны чыгару технологияләрен эшләү срогы җир асты байлыкларыннан файдаланучы инициативасы буенча озайтылулар санын чикләмичә 5 елга кадәр вакытка озайтыла.»;

10 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Предприятиене яки җир асты корылмаларын тулысынча яки өлешчә бетерү яки консервацияләгәндә тау эшләнмәләре һәм бораулау скважиналары халыкның тормышы һәм сәламәтлеге иминлеген, әйләнә-тирә мохитне, биналарны һәм корылмаларны саклауны, ә консервацияләгәндә шулай ук ятманың, тау эшкәртмәләренең һәм бораулау скважиналарының сакланышын тәэмин итә торган халәткә китерелергә тиеш. Тау эшләп чыгаруны бетерү өчен, тау токымнарын тоташтыручы һәм сыйдырышлы тау токымнары, тау токымнарын юкка чыгару проекты нигезендә куркыныч янаган IV һәм V класслы кара металл җитештерү калдыклары файдаланылырга мөмкин.»;

13 пунктның беренче абзацына «, законнарда каралган очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

14 пунктка «, продукцияне бүлү турында килешү шартларында җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирелгәндә - мондый килешү үз көченә кергән көннән соң» сүзләрен өстәргә.»;

Тәртипкә түбәндәге эчтәлекле $14^1$ - $14^3$ пунктчалар өстәргә:

«$14^1$. Файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запаслары, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик мәгълүмат дәүләт экспертизасы узарга тиеш, моңа эчәргә яраклы су белән тәэмин итү яисә техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган җир асты сулары запаслары һәм аларны чыгару күләме тәүлегенә 100 куб метрдан артмаган җир асты суларын чыгару өчен бирелә торган җир асты сулары запаслары, шулай ук авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны эшкәртү процессында чыгарыла торган авыр чыгарыла торган файдалы казылмалар запаслары керми.

$14^2$. Файдалы казылмалар һәм җир асты суларын чыгару аларның запасларына дәүләт экспертизасы үткәрелгәннән соң гына рөхсәт ителә, моңа эчәр сулар белән тәэмин итү яисә техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм аларны чыгару күләме тәүлегенә 100 куб метрдан артмаган җир асты суларын чыгару керми, шулай ук авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм кыен чыгарыла торган файдалы казылмаларны чыгару технологияләрен эшләү барышында табудан тыш.

14$^3$. Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга бирелә торган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына, шулай ук эчәргә яраклы су белән тәэмин итү яисә техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган гомумтаралган файдалы казылмалар запасларына һәм җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы үткәрү һәм аларны чыгару күләме тәүлеккә 500 куб метрдан артмаган җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы үткәрү «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 29 статьясындагы сигезенче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә «Җир асты байлыклары турында» 2005 елның 11 февралендәге 69 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең файдалы казылмалар һәм җир асты байлыклары запаслары экспертлары турында» 2005 елның 11 февралендәге 69 номерлы карарының 2 пункты нигезендә җир асты байлыкларыннан файдалану, җир асты байлыкларыннан файдалану һәм җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану турында мәгълүмат тапшыруның күләме һәм аның кертеме күләмендә гамәлгә ашырыла.»;

15 пунктта «яисә сәнәгать объектларын йә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны су белән технологик тәэмин итү» сүзләрен «яисә техник су белән тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин